ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 елның 5 апреле**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 874**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 8 нче йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында » 2015 елның 3 декабрендәге 2660 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

ТР Зеленодольск шәһәренең Ленин урамындагы, 8 нче йортны авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программадан чыгару белән бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетның «Зеленодольск муниципаль районында авария хәлендәге күпфатирлы йортлар исемлеген раслау турында» 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы Зеленодольск муниципаль районы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 21 июнендәге 1637 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 8 нче йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында » 2015 елның 3 декабрендәге 2660 номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга.

2. . Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы органга;
- «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ;
- торак урыннар милекчеләренә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыруны һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo. tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының(http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштыруны тәкъдим итәргә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин